АРБОР ТӨП БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

**Әниләр көненә багышланган концерт программасы**

Төзеде: Мифтахова Руфия Бильсур кызы,

2022

1. Әниләргә багышланган шигъри композиция.

   **Җыр** “Биргәнсең син миңа ал нурын таңнарның”

   Талгын музыка астында:

1 а.б  Хәерле кич, хөрмәтле тамашачылар!

Салкын кышларга кереп барганда, без иң җылы һәм якты бәйрәмнәрнең берсен - Әниләр көнен билгеләп үтәбез.

2 а.б. Безгә тормыш бүләк иткән, бөтен йөрәк җылысын биргән, безнең өчен тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр кичергән газизләребезгә нинди генә теләкләр теләсәк тә аз булыр сыман.

1 а.б. Тормышыбыз бизәге булган әниләребез матур да, батыр да, мәрхәмәтле дә, изге күңелле дә.

Еллар үтеп, үзебез әти-әниләр булсак та, без төпле киңәшләр сорап сезнең янга киләбез, сезнең һәрчак безне аңлавыгызны, ярдәмегездән ташламавыгызны беләбез.

2 а.б. Сез гаилә учагын, тынычлыкны саклаучылар.

Балалар  гына түгел, ә  бөтен  җәмгыять аналар канаты  астында.

Мәхәббәтегез, сабырлыгыгыз,  назыгыз һәм ниләр генә кылсак та гафу итә белүегез өчен сезнең алда баш иябез.

1 а.б. Сезнең  иңнәргә бик зур йөк - гаилә мәшәкатьләре дә, һөнәри эшчәнлек тә, балалар тәрбияләү дә төшә.  Барысы өчен дә бик зур рәхмәт!

2 а.б. Кадерледән  кадерлеләребез!

Сезгә озын гомер,  имин көннәр, балаларыгызның куанычларын гына күреп яшәвегезне телибез. Күңелегез тыныч, килер көннәрегез матур һәм һәрчак бәхетле булыгыз!

1 а.б. Хәзер яңгыраячак җырыбыз сезгә бәйрәм сәламе булып яңгырасын.

**<u>Җырлый  Ралия  Габделхакова</u>**

**Эчтән  генә  Руфия:**  Җир йөзендә барлык әниләр

Бәхетле яшәсен дип телик

Балалары  куандырып  торсын

Китерсеннәр бары игелек.

Әни көне — шундый матур бәйрәм

Барлык әниләргә баш иик

Күзләрендә бәхет нуры һәрчак

Сүнми балкып торуын телик.

**Сәхнәдә - Гөлчәчәк Галиева “Кыйбла” Ш.Җиһангирова шигыре**

**1а.б.** Бар хәстәрем, бар хәсрәтем – бала өчен,
Хөрмәтем дә, хезмәтем дә – бала өчен.
Үкенүләр, үтенүләр – бала өчен,
Тынгысыз көн, йокысыз төн – бала өчен.

2 а.б. Утка, суга укталуым – бала өчен,
Чыгар юлдан тукталуым – бала өчен.
Таңнан әүвәл кайнар аш та – бала өчен,
Тәгәрәгән кайнар яшь тә – бала өчен.

1 а.б. Иртән-кичен йөрәк хисем – бала өчен,
Барлык эшем, барлык көчем – бала өчен,
Янам, түзәм, янам, көям – бала өчен,
Горур башым түбән иям – бала өчен.
Төнен якты таңнар көтәм – бала өчен,
Күңелемдә җырлар йөртәм – бала өчен.

**Җырлый Зәлидә Галимова**

1 а.б. Бүгенге бәйрәм кичендә һәркемнең күңеле Әнисенә булган җылы, назлы, якты хисләрдән мөлдерәмә тулыдыр. Изге теләкләр, матур сүзләрне Әниләргә җиткерәсе килү теләге белән янасыздыр. Безнең читтә яшәгән авылдашларыбыз да үзләренең матур теләкләрен Әниләренә җиткерергә уйлаганнар. Армиядә хезмәт итүче улыннан, читтә яшәүче кызыннан котлау сүзләре ишетү – зур бәхеттер ул! Хәзер шул котлауларны тыңлап үтик әле. (Котлаулар)

**Гөлчәчәк:** Әни, әнием, әнкәй! Кадерләп, назлап әйтәбез, күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз. Һәрвакыт яныбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз Әниләребезгә  без гомер буе бурычлы.

Халык ана хакын хаклауны Алла хакын хаклау белән янәшә куя.  “Ананңы арка кочып Мәккәгә алап барсаң да, бурычыңны үтәп җиткерә алмассың”. “Анаң өчен учыңда тәбә куырсаң да, хакын түләп бетерә алмассың”. Гасырлар аша килеп ирешкән бу гыйбрәтле, канатлы сүзләрне җаныбызга, аңыбызга сеңдерү зарур. Ана хакын хаклап яшәсәк иде.

**Сәхнәгә  җырчыбыз Фирдәвес  Галиева  чакырыла**

2 а.б. Әни!
Иң  матур юллар –
Син  йөргән юллар.
1.а.б.Иң тәмле сулар –
Син  биргән  сулар.
2 а.б.Иң  йомшак  куллар –
Син  сөйгән  куллар.
1 а.б. Иң якты  моңнар –
Син  белгән  моңнар.
2 а.б.Иң  кайнар  эзләр –
Син  баскан  эзләр.
1 а.б.Иң  моңлы  күзләр –
Син  баккан  күзләр.

2 а.б.Иң  тугры сүзләр –
Син  әйткән  сүзләр.
1 а.б. Иң  сабыр  йөрәк –
Синең  йөрәгең.
2 а.б. Иң  талмас  беләк –
Синең  беләгең.
1 а.б. Иң  изге  теләк –
Синең  теләгең.
2.А.б. Иң  бөгелгән  бил –
Ул  синең  билең.
1. А.б.Гөл  сибелгән  тел –
Ул  синең  телең.
2.а.б.Үч тотмас  күңел –
Синең  күңелең, Әни!

**Татарча  бию**

**Руфия  шигырь сөйли**

Сәхнәдә -  җырчыбыз  **Гөлнара  Гарипова**

**Җыр: Гөлнара  Гарипова**

2 а.б. Әни! Олы юлларга чыгып киткәндә, хәерле сәгатьләр теләп калучы ул.

Әни! Авырганда синең урыныңа үзе авырырга әзер торучы. Ходайдан сиңа җиңеллекләр сораучы ул.

1 а.б. Әни! Кулларын туңганда — өреп җылытучы.

Йөрәгең елаганда — сүз белән бәгырь ташларын эретүче.

2 а.б. Хәсрәт килгәндә — җиңеләйтүче.

Шатлык килгәндә — синнән дә артыграк сөенүче.

1 а.б. Беркемгә чишмәгән серләреңне күзеңнән укучы.

Беркемгә аңлатмаган әлеге серләрне шунда ук аңлаучы.

2 а.б.Бөтен дөнья синнән баш тартканда да, синнән йөз чөермәүче. Соңгы сулышында да синең исемеңне атаучы. Хәер-фатыйхасын биреп калырга тырышучы.

**Мари биюе**

2 а.б. Балагызның берәве сез,
Гаиләнең йөрәге сез,
Иминлекнең терәге сез.
Һәркемнең иң кирәге сез.
Сез чаялар, сез батырлар
Сез дөньяда иң матурлар.
Сез булганга тормыш ямьле,
Сез булганга яшәү гамьле.

Бәйрәмнең кайсы да тәнгә җиңеллек,рәхәтлек,җанга ял бирә. Шушы бәйрәм көне күңелегезгә шатлык,тәнегезгә сихәтлек, өегезгә иминлек алып килсен, дигән теләктә җыр тапшырабыз. **Җырлый Гөлнара Низамова**

**Гөлчәчәк шигырь**

**Руфия:.** Әни – җирдә иң газиз, иң якын кеше, чөнки ул сине тудырган, күкрәк сөтен имезгән, җыр көйләп бишектә тибрәткән, беренче елмаюыңны күреп куанган, туган телне өйрәткән, халык моңын күңелеңә сеңдергән. Әниләрнең сиңа кылган изгелеген

санап бетерү мөмкинме соң? Көннең яктылыгы-кояшта, күкнең матурлыгы-йолдызларда, җирнең гүзәллеге-хатын-кызларда. Кадерлик без әниләрне, олылыйк! Аларның канатлары каерылмасын, тормыш авырлыкларыннан иңнәре сыгылып төшмәсен! Хатын-кыз һәрвакытта да хатын-кыз булып калсын!

**Концерт номеры скетч**

1.а.б Менә син иртә белән йокыдан уяндың да күзләреңне ачтың. Бүлмә кояш нуры белән балкып тора. Өйдә тәмле аш исе аңкый. Сиңа бик рәхәт. Син шул вакытта үзең дә сизмәстән, "әни" дип эндәшәсең. Нигә? Чөнки хәзер бу иртәнге сәгатьтә синең йөрәгеңдә шатлык тыпырчына һәм ул менә хәзер "әни" дигән сүз булып синең күкрәгеңнән очып чыкты да ананың күңеленә барып кунды. Ананың йөзе елмайды, күзләре энҗе кебек ялтырап китте. Нигә? Чөнки "әни" дигән сүз белән аңа иртәнге сәгать тагы да матуррак булып китте. Аның күңеле татлы хисләр белән тулды.

2 а.б. Әни… Нинди олы сүз бу! Кеше үз гомереңдә шул сүзне ничәмө-ничә кабат әйтә икән? Әйткән саен, сүз яңадан-яңа мәгънә алып килә. Ана шул бер сүздән синең шатлыгыңны да, кайгыңны да, уйларыңны да белә. Алай гына да түгел, ана бу сүз аша синең йөрәгеңне күрә. Әйе, күрә. Чөнки, "әни" дигән сүз ул үзе йөрәктә туа. Ә йөрәктән чыккан сүз йөрәккә барып керә. Әни дип әйттеңме, син инде көчле дә, син инде бәхетле дә!

**Сәхнәдә җырчыбыз Раушания Кабирова**

**Гөлчәчәк:** Котлы булсын, әни бәйрәмең,
Матур булып атсын таңнарың.
Рәхәт яшә, игелеге кайтсын
Син үстергән һәрбер баланың.
Ак бәхетләр юлдаш булсын сиңа,
Көннәреңне шатлык бизәсен.
Сәламәтлек – үзе бәхет бит ул,
Ходай шуннан мәхрүм итмәсен.

**Әниләр хөрмәтенә Кызлар ансамбле башкаруында "Әнием" җыры яңгырый**

2 а.б.. Кем дөньяга кеше бүләк итә,
Ә кешегә якты дөньяны?
Тойгылары кояш кебек кайнар,
Эретерлек гранит кыяны?

1 а.б. Кем күңеле тулган айдай серле,

Язлар сыман назлы, ягымлы?

Шатлыкларын башкаларга бүлеп,

Кайгыларга түзем, сабырлы?

2 а.б. Кем елмая җәйге таң аткандай,

Балкып китә шундук тирә-як?

Нәфислеге гөлләр сокланырлык,

Көләчлектә аңа тиңнәр юк?

1 а.б. Кем куллары өйне, җирне ямьли,

Изгелеге үлчәү тапкысыз?

Ул, әлбәттә, яшәү чыганагы,

Тормыш яме — Әнкәй, хатын-кыз!

**Җырлый Фирдәвес Галиева һәм Зәлидә Галимова**

2.а.б. Хөрмәтле тамашачылар, кадерле Әниләр, бәйрәм кичәбез ахырына якынлашты. Сезгә тазалык-саулык, җан тынычлыгы, бәрәкәтле имин көннәр теләп саубуллашабыз.

1.а.б. Әниләребезне бәйрәм көнне генә түгел, гомеребез буе кадерләп, хөрмәтләп яшәсәк иде. Сау булыгыз. Кабат очрашулар насыйп булсын.

**Әниләр көненә багышланган концерт программасы**

1. **Шигъри композиция. Җыр “Биргәнсең син миңа ал нурын таңнарның”**

2. **Җыр: Ралия Габделхакова**

3. **Шигырь: Гөлчәчәк Галиева**

4. **Җыр: Зәлидә Галимова**

5. **Җыр: Фирдәвес Галиева**

6. **Бию: Татарча**

7. **Шигырь: Руфия Мифтахова**

8. **Җыр: Гөлнара Гарипова**

9. **Бию: Мари**

10. **Җыр: Гөлнара Низамова**

11. **Шигырь: Гөлчәчәк Галиева**

12. **Скетч**

13. **Җыр: Раушания Кабирова**

14. **Җыр: Кызлар ансамбле**

15. **Җыр: Фирдәвес Галиева һәм Зәлидә Галимова**